**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3369**
**25.04.2023**

Башкарма комитетның 2019 елның 29 июлендәге 3864 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю урынын (мәйданчыгын) булдыруны килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2019 елның 29 июлендәге 3864 номерлы карары (Башкарма комитетның 2021 елның 25 мартындагы 2051 номерлы карары редакциясендә) белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю урынын (мәйданчыгын) булдыруны килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбулада «Башкарма комитетның 2016 елның 13 маендагы 2363 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлеге» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 1.4 пунктта:

- 4, 10 пунктчалар үз көчен югалткан дип танырга;

- 12 пунктчаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«12. Башкарма комитетның 2021 елның 1 августындагы 246-р номерлы боерыгы белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының эш регламенты (алга таба – Эш регламенты);»;

- 13 пунктчаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«13. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2020 елның 25 февралендәге 101-р номерлы боерыгы белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре (алга таба – Эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре).»;

3) 2.1 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «2.1. Муниципаль хезмәтнең исеме | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю урынын (мәйданчыгын) булдыруны килештерү | »; |

4) 3.3.1 пунктның икенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;
5) кушымтаны (белешмә) яңа редакциядә бәян итәргә:

«

Кушымта
(белешмә)

МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮ ӨЧЕН
ҖАВАПЛЫ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРНЫҢ
РЕКВИЗИТЛАРЫ

Башкарма комитетның районнар хакимиятләре

| № т/б | Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|---|
| Комсомол районы | | | |
| 1. | Район хакимияте Башлыгы | 70-34-27 | ikkr@mail.ru |
| 2. | Район хакимияте Башлыгы урынбасары | 71-40-11 | ikkr@mail.ru |
| 3. | Бүлекнең әйдәүче белгече | 71-42-24 | ikkr@mail.ru |
| Үзәк районы | | | |
| 1. | Район хакимияте Башлыгы | 47-55-33 | ispolkom_cr-Nch@mail.ru |
| 2. | Район хакимияте Башлыгы урынбасары | 47-55-61 | ispolkom_cr-Nch@mail.ru |
| 3. | Бүлекнең әйдәүче белгече | 47-55-49 | ispolkom_cr-Nch@mail.ru |
| Автозавод районы | | | |
| 1. | Район хакимияте Башлыгы | 56-50-71 | avtoispolcom@mail.ru |
| 2. | Район хакимияте Башлыгы урынбасары | 32-98-42 | avtoispolcom@mail.ru |
| 3. | Бүлекнең әйдәүче белгече | 54-76-76,<br>32-98-36 | avtoispolcom@mail.ru». |

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның Үзәк районы хакимияте Башлыгы Э.Р. Фәттаховка, Башкарма комитетның Автозавод районы хакимияте Башлыгы В.Х. Харисовка, Башкарма комитетның Комсомол районы хакимияте Башлыгы Л.И. Әхмәтҗановка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов